**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Шәмәк авыл җирлегенең Кече Шәмәк торак пунктында булган**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**20 ноябрь, 2020** **№ 2**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 56, 25.1 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Шәмәк авыл җирлегенең Кече Шәмәк торак пунктында булган гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Олы Шәмәк авыл җирлегенең Кече Шәмәк торак пункты территориясендә, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, балачактан инвалид, күп балалы гаиләләр һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан һәм Россия Федерациясенең армия сафларында хезмәттә булучылардан кала, Тәтеш муниципаль районы Олы Шәмәк авыл җирлегенең Кече Шәмәк торак пункты территориясендә яшәү урыны буларак теркәлгән һәр балигъ булган гражданнан үзара салымга 1000 сум күләмендә акча җыелуны кертергә.
2. гражданнарның үзара салым акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне чишү өчен юнәлдерергә:
   - Урам-юл челтәрләрен норматив халәткә китерү;
   - Зират территориясе коймаларын ремонтлау.
3. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы”нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырып халыкка җиткерергә.

**Гражданнар җыенында**
**рәислек итүче,**
**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Олы Шәмәк авыл җирлеге**
**башлыгы** **А.И. Афанасьев**